КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 3 август г.Казань № 642

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ел инженеры» республика конкурсын үткәрү турында» 2019 ел, 22 апрель, 325 нче карары белән расланган «Ел инженеры» республика конкурсы хакында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ел инженеры» республика конкурсын үткәрү турында» 2019 ел, 22 апрель, 325 нче карары белән расланган «Ел инженеры» республика конкурсы хакында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлекнең 2.1 пунктындагы 2.1.2 пунктчасында «яшь» сүзен төшереп калдырырга;

3 бүлекнең 3.1 пунктындагы 3.1.2 – 3.1.3 пунктчаларында «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

5. Конкурста катнашуга гаризалар бирү тәртибе

5.1. Конкурста катнашу өчен кандидатуралар кандидат төп эш (уку) урыны буенча югары белем бирү оешмалары, предприятие яки оешма җитәкчелеге тарафыннан тәкъдим ителә.

5.2. Конкурста катнашу өчен гариза түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

5.2.1. Катнашучының һөнәри казанышлары турында дәлилләнгән бәяләмәне һәм предприятиенең яки оешманың фирма бланкында рәсмиләштерелә торган конкрет кандидатура күрсәтү турында тәкъдим итү категорияне һәм тәкъдим итү номинациясен үз эченә алган карар-тәкъдим.

5.2.2. Кадрларны исәпкә алу буенча белешмә-объективка яки шәхси бит;

5.2.3. Россия Федерациясе гражданының шәхесен раслаучы төп документ күчермәсе;

5.2.4. Күчермәләре турында югары белем, гыйльми дәрәҗә турында дипломнар күчермәләре яки югары белем бирү оешмасы уку турында белешмә;

5.2.5. Алдагы календарь елы яки конкурска тәкъдим ителә торган төгәл бер инженерлык эше йомгаклары буенча кандидатның инженерлык, фәнни эшчәнлекләрендә кандидатның казанышларын тасвирлау (А4 форматындагы ике биттән артмаган белешмә рәвешендә бирелә);

5.2.6. Басма һәм электрон фәнни һәм фәнни-техник басмаларда кандидат тарафыннан бастырып чыгарылган алдагы календарь ел өчен фәнни хезмәтләр исемлеге, уйлап табуларга патентлар исемлеге, файдалы модельләр, ЭВМ программаларын теркәү турында сәнәгать үрнәкләре һәм таныклыклар исемлеге (документлар күчермәләрен яки электрон рәвештәге документларны кушып санлаштырылган китапханә исемлеге рәвешендә рәсмиләштерелә);

5.2.7. Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;

5.2.8. 4 х 6 см үлчәмдәге ике төсле фотография.»;

6 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Конкурс комиссиясе һәм аның эш тәртибе

6.1. Конкурсантларны бәяләү конкурс комиссиясе (алга таба – комиссия) тарафыннан башкарыла, аның составына алдынгы галимнәр, инженерлар, халык хуҗалыгының төрле тармаклары белгечләре керә.

6.2. Конкурс комиссиясе рәистән, рәис урынбасарыннан, комиссия әгъзаларыннан һәм секретареннән тора. Комиссия рәисе комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә һәм аның утырышларын үткәрә. Комиссия рәисе вакытлыча булмаган чорда эшчәнлек белән комиссия рәисе урынбасары җитәкчелек итә. Комиссия әгъзалары аның утырышларында алыштыру хокукыннан башка катнаша. Комиссия утырышы, әгәр анда әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы санала.

6.3. Утырышта комиссия әгъзасы булмаган очракта ул комиссия рәисенә карап тикшерелә торган торган мәсьәләләр буенча үз фикерен язмача тапшырырга хокуклы.

6.4. Конкурс комиссиясе гаризаларны ачык тавыш бирү юлы белән бәяли. Комиссия карары утырышта катнашучы әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавыш тигез булган очракта комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

6.5. Комиссия утырышларында кабул ителә торган карарлар утырышта рәислек итүче имзалый торган беркетмәләр рәвешендә рәсмиләштерелә.

6.6. Конкурс комиссиясе әлеге Нигезләмәнең 5.2 пунктына туры килми торган документлар тапшырган очракта катнашучы гаризасын кире кагарга хокуклы.»;

7 бүлектә:

исемендә «Конкурста катнашучыларны сайлап алу» сүзләрен «конкурста катнашучыларны бәяләү» сүзләренә алмаштырырга;

7.1 пунктта «Бәяләү» сүзе алдыннан «Конкурсантларны» сүзен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 7.1.10 – 7.1.13 пунктчалар өстәргә:

«7.1.10. Конкурсантның җитештерү эшчәнлегендә кулланыла торган җиһазларның һәм технологик процессларның техник характеристикаларын һәм параметрларын, аларның үзенчәлекләрен һәм иң яхшы аналоглары белән чагыштырма дәрәҗәләрен белү;

7.1.11. Заманча фән һәм техника казанышлары, сәнәгый куркынычсызлык һәм техник эстетика стандартлары, нормалары һәм кагыйдәләре таләпләренә туры китереп яңа продукция эшләүдә һәм үзләштерүдә катнашу;

7.1.12. Җентекле технологик процессларны һәм цехара бәйләнешларның тулы исемлеген үз эченә алган җитештерү схемасын төзү сәләте;

7.1.13. «Сакчыл җитештерү» принципларын белү һәм куллану, 5S инструментлары белән эшли белү.»;

7.2 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

8 бүлектә:

бүлек исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Конкурс үткәрү һәм лауреатларны бүләкләү тәртибе»;

8.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.1. Конкурс ике турда категория һәм номинацияләр буенча үткәрелә. Беренче тур барышында конкурс комиссиясе тарафыннан конкурсантлар тәкъдим иткән документларны эксперт бәяләве үткәрелә. Икенче тур кысаларында конкурсантлар шәхси казанышлар яисә төгәл бер инженер эшен яклау белән күчмә семинар үткәрелә, аларның тасвирламалары әлеге Нигезләмәнең 5.2 бүлегендәге 5.2 пунктның 5.2.4 пунктчасы нигезендә конкурска тәкъдим ителгән.»;

8.2 пунктка «һәр критерий буенча җыелган баллар суммасы буенча» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин